Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге Советы Карары

9 март 2020 ел
Кышлау авылы

№ 121

Кышлау авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августындагы 54 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советы Карар бирә:

1. 2017 елның 22 августындагы 54 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 1 пунктта «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы» сүзләрен төшереп калдырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының "Кышлау авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы — Р. Ф. Шакирова